БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 11 2024 ел № 278

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 1360 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2024елның 30 июлендәге 198 номерлы карары белән расланган, Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Бюджет керемнәре администраторының Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасының исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан бюджетка түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында әзерләнгән белешмәсе (1 нче кушымта);

1.2. 4.2 пунктта «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган» сүзләрен өстәргә;

1.3. 4.3 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Штраф яки суд акты рәвешендә җәза алуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү акты, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән вакыты чыгуга бәйле рәвештә;»;

1.4. 4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«Гражданның судтан тыш банкротлык процедурасын төгәлләү турында Бердәм федераль реестрдан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән очракларда).»;

1.5. 11 пунктны «акт белән рәсмиләштерелә» сүзләреннән соң «(3 нче

кушымта)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.6. 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.7. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 3 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «20» 11
278 номерлы карарына
1 нче кушымта

Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район бюджетына түләүләрне түләү буенча исәпкә алына торган бурычларның суммалары турында белешмәсе

______________________________________________________________
(оешманың исеме (ИНН/КПП), физик затның Ф.И.О., (ИНН булган очракта)
____________елга торышы буенча

| № т/б | (КБК) | Түләү төре | Түләүне түләү буенча бурыч барлыкка килү датасы (вакыты) | Түләү буенча барлык бурыч | шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Төп бурыч | Пеня лар | [illegible] |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | |

Рәис
_______________ ___________/______________________________
(имза) (Ф.И.О.)

Мөһер урыны

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «26» 11
278 номерлы карарына
2 нче кушымта

Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләп бетерүгә өметсез дип тану турында
АКТ

"______" __________20___ел №_____

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

*(оешманың тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)* ___________________________________________________________________

*(ИНН, ОГРН, КПП)*

Бурыч барлыкка килгән түләү турында белешмәләр:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

*(КДБ һәм аның тулы исеме)*

Бурыч суммасы __________ сум _______ тиен тәшкил итә, шул исәптән
пенялар буенча - __________ сум ______ тиен, штрафлар - _________ сум ___ тиен.

______________________________________________________________________________

________________________________________________________ нигезендә:
(реквизитларны күрсәтеп, конкрет документлар күрсәтелә)

Комиссия рәисе: ________________/__________/________________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*

Комиссия рәисе урынбасары: ________________/__________/________________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*

Комиссиянең җаваплы секретаре: ________________/__________/________________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*

Комиссия әгъзалары:

______________________/______________/__________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*

______________________/______________/__________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*

______________________/______________/__________________
*(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.О.)*